ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18 декабрь 2013 Казан ш. 6-45/тэ №лы

***Татарстан Республикасы территориясендә челтәр оешмаларының электр челтәрләренә технологик тоташу өчен стандарт тариф ставкалары һәм түләү формулаларының билгеләнүе турында***

«Электроэнергия турында» 26 март 2003 35-ФЗ №лы федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электроэнергиягада көйләүле бәяләре (тарифлары) өлкәсендә бәя билгеләнүе турында» 29 декабрь 2011 1178 №лы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 29 декабрь 2004 861 №лы карары белән расланган электр челтәрләргә электр энергия кулланучыларының электр алучы җиһазларның, электр энергия җитештерүче объектларның, челтәр оешмалары һәм башка шәхесләр ия булган электр челтәр хуҗалыкларының объектларына технологик тоташу кагыйдзләре, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең «Электр челтәрләргә технологик тоташу өчен түләү күләменең билгеләнүе буенча методик күрсәтмәләренең раслануы турында» 11 сентябрь 2012 209-э/1 №лы әмере буенча, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15 июнь 2010 468 №лы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә таянып Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты БОЕРА:

1. 01 январь 2014 башлап 31 декабрь 2014 хәтле әлеге карарның 1 кушымтасы буенча Татарстан Республикасы территориясендә челтәр оешмаларының электр челтәрләренә технологик тоташу өчен «$C_1$» стандарт тариф ставкаларын билгеләргә.

2. 01 январь 2014 башлап 31 декабрь 2014 хәтле әлеге карарның 2 кушымтасы буенча әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы территориясендә челтәр оешмаларының электр челтәрләренә технологик тоташу өчен «соңгы миля» («$C_2$» - «$C_4$») чаралары буенча стандарт тариф ставкаларын билгеләргә.

3. 01 январь 2014 башлап 31 декабрь 2014 хәтле әлеге карарның 3 кушымтасы буенча әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы территориясендә челтәр оешмаларының электр челтәрләренә технологик тоташу өчен түләү формуласын билгеләргә.

4. 01 январь 2014 елыннан башлап түбәндәгеләрне гамәлдән чыкан дип таныргa:

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы территориясендә «Оборонэнерго» ААҖ «Волго-

Вятский» филиалының челтәрләренә технологик тоташу өчен түләүнең исәп-хисабы өчен стандарт тарифлар ставкаларының һәм формуларының билгеләнүе турында» 25 декабрь 2012  6-34/тп №лы карары;

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы территориясендә «Россия тимер юллары» ААҖ челтәрләренә технологик тоташу өчен түләүнең исәп-хисабы өчен стандарт тарифлар ставкаларының һәм формуларының билгеләнүе турында» 9 август 2013  6-17/тп №лы карары;

5. Әлеге карар рәсми рәвештә нәшер ителү көненнән сон ун көн эчендә көченә керә.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитеты
карарының Кушымтасы;
18 декабрь 2013  6-45/тп №лы

Татарстан Республикасы территориясендә челтәр оешмаларының электр челтәрләренә технологик тоташу өчен «$C_1$» стандарт тариф ставкалары <1>

| Татарстан Республикасында Челтәр оешмаларының атамалары | $C_1$, сум/кВт (НДС керми) | |
|---|---|---|
| | тоташтырыла торган электр алучы җиһазларның челтәр оешмасының һәм җиһазлар хуҗасының катнашуында технологик күзәтү буенча башкарма хакимиятенең федераль органыны вазифалы шәхесе тарафыннан тикшерелү очрагында <2> | тоташтырыла торган электр алучы җиһазларның челтәр оешмасының һәм җиһазлар хуҗасының катнашуында технологик күзәтү буенча башкарма хакимиятенең федераль органыны вазифалы шәхесе тарафыннан тикшерелү очрагы булмаганда |
| «Алабуга» сәнагый җитештерү тибындагы махсус иктисади зона» ААҖ | 8,07 | 9,52 |
| «Россия тимер юллары» ААҖ | 80,97 | 92,19 |
| «Газпром энерго» ҖЧҖ | 124,20 | 127,10 |
| «Оборонэнерго» ААҖ «Волго-Вятский» филиалы | 76,03 | 85,58 |

<1> «$C_1$» стандарт тариф ставкасы 35кВ көчәнеш дәрәҗәсендә 8900 кВт максималь көч тоташтырылганда, шулай ук вакытлыча технологик тоташу очрагында кулланыла.

<2> әлеге ставка түбәндәгеләр өчен технологик тоташу өчен түләүнең исәп-хисабы ясалганда кулланыла:

- юридик шәхес яки шәхси эшмәкәр, өченче дәрәҗә ышанычлыгы буенча (электр тәэмин чыганакларының берсе буенча) 10 кВт хәтле булган көчәнеш дәрәҗәсендә 670 кВт соралган көчне кушып (элегрәк ул ноктага тоташтырылган электр алучы җиһазларны исәпкә алып);
- вакытлыча технологик тоташу максаты белән гариза бирүчеләр;
- физик шәхес, өченче дәрәҗә ышанычлыгы буенча (электр тәэмин чыганакларының берсе буенча) 20 кВт хәтле булган көчәнеш дәрәҗәсендә 15 кВт соралган көчне кушып (элегрәк ул ноктага тоташтырылган электр алучы җиһазларны исәпкә алып), гариза бирүченең участогы чикләре белән челтәр оешмасының электр челтәр хуҗалыгының объектлары арасында шәһәрдә иң күп 300 метр һәм авыл җирлегендә 500 метр булырга тиеш;

Искәрмә. 2014 елның бәяләре белән исәпләнгән $C_1$ стандарт тариф ставкасы

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының карарларының алыну оештыру, тикшерү һәм алып бару бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитеты
карарының Кушымтасы;
18 декабрь 2013  6-45/тп №лы

# Татарстан Республикасы территориясендә челтәр оешмаларының электр челтәрләренә технологик тоташу өчен («$C_2$» - «$C_4$») «соңгы миля» чаралары буенча стандарт тариф ставкалары

1. $C_2$ - 1 км линия исәпләп электр тапшыру һава линиясен төзүгә челтәр оешманың чыгымнарын каплауга стандарт тариф ставкасы:

| Көчәнеш диапозоннары, кВ | Тоташтырылган көч, кВт | Стандарт тариф ставкасы, сум/км(НДС керми) |
|---|---|---|
| 0,4 | 150 кадәр кушып | 110 479,00 |
| | 150 дән 670 кадәр кушып | 158 828,00 |
| | 670 тән югары | 158 828,00 |
| 6 - 10 | 150 кадәр кушып | 182 259,00 |
| | 150 дән 670 кадәр кушып | 260 779,00 |
| | 670 тән югары | 265 089,00 |

2. $C_{3тр}$ - 1 км линия исәпләп электр тапшыру чыбык линиясен төзүгә челтәр оешманың чыгымнарын каплауга стандарт тариф ставкасы:

| Көчәнеш диапозоннары, кВ | Тоташтырылган көч, кВт | Стандарт тариф ставкасы, сум/км(НДС керми) |
|---|---|---|
| 0,4 | 150 кадәр кушып | 243 805,00 |
| | 150 дән 670 кадәр кушып | 259 784,00 |
| | 670 тән югары | 354 291,00 |
| 6 - 10 | 150 кадәр кушып | 397 575,00 |
| | 150 дән 670 кадәр кушып | 471 504,00 |
| | 670 тән югары | 507 419,00 |

3. $C_{3тр}$ - 1 км линия исәпләп горизонталь-юнәлешле боралау методы белән электр тапшыру чыбык линиясен төзүгә челтәр оешманың чыгымнарын каплауга стандарт тариф ставкасы:

| Көчәнеш диапозоннары, кВ | Тоташтырылган көч, кВт | Стандарт тариф ставкасы, сум/км(НДС керми) |
|---|---|---|
| 0,4 | 150 кадәр кушып | 617 458,00 |
| | 150 дән 670 кадәр кушып | 653 249,00 |
| | 670 тән югары | 670 296,00 |
| 6 - 10 | 150 кадәр кушып | 793 687,00 |
| | 150 дән 670 кадәр кушып | 932 992,00 |
| | 670 тән югары | 1 076 449,00 |

4. $C_{4пс}$ - 1 км секцияләү пунктларын төзүгә челтәр оешманың чыгымнарын каплауга стандарт тариф ставкасы:

| Көчәнеш диапозоннары, кВ | Тоташтырылган көч, кВт | Стандарт тариф ставкасы, сум/км(НДС керми) |
|---|---|---|
| 0,4 | 150 кадәр кушып | 21,00 |
| | 150 дән 670 кадәр кушып | |
| | 670 тән югары | |
| 6 - 10 | 150 кадәр кушып | 397,00 |
| | 150 дән 670 кадәр кушып | |
| | 670 тән югары | |

5. $C_{4тп}$ - 1 км подстанцияләр төзүгә челтәр оешманың чыгымнарын каплауга стандарт тариф ставкасы:

| Көчәнеш диапозоннары, кВ | Тоташтырылган көч, кВт | Стандарт тариф ставкасы, сум/км(НДС керми) |
|---|---|---|
| 0,4 | 150 кадәр кушып | 451,00 |
| | 150 дән 670 кадәр кушып | 724,00 |
| | 670 тән югары | 899,00 |
| 6 - 10 | 150 кадәр кушып | 451,00 |
| | 150 дән 670 кадәр кушып | 724,00 |
| | 670 тән югары | 905,00 |

Искәрмә. 2001 елның бәяләре белән исәпләнгән $C_2$ – $C_4$ стандарт тариф ставкалары

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының карарларының алыну
оештыру, тикшерү һәм алып бару бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитеты
карарының 3 Кушымтасы;
18 декабрь 2013 6-45/тп №лы

Татарстан Республикасы территориясендә челтәр оешмаларының электр челтәрләренә технологик тоташу өчен түләү формулалары

Стандарт тариф ставкаларны кулланып, технологик тоташу өчен түләүләр түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$P = C_1 * N + (C_2 * L_2 + C_{3тр} * L_{3тр} + C_{3\ гнб} * L_{3\ гнб} + C_{4пс} * N + C_{4тп} * N) * Z,$$

анда:

$C_{1(2,3тр,3гнб,4пс,4тп)}$ – әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән «Россия тимер юллары» ААҖ челтәрләренә энергия кулланучыларының электр алучы җиһазларның, электр энергия җитештерүче объектларның, челтәр оешмалары һәм башка шәхесләр ия булган электр челтәр хуҗалыкларының объектларына технологик тоташу өчен түләүләрне исәпләнүе өчен стандарт тариф ставкалары;

N – кулланучыларның , электр энергия җитештерүче объектларның, челтәр оешмалары һәм башка шәхесләр ия булган электр алучы җиһазларның тоташтырылган максималь көчнең күләме;

$L_{2\ (3тр,\ 3гнб)}$ – электр тапшыруның һава һәм чыбык линияләренең озынлыгы;

Z – Россия Федерациясе Региональ үсеш Министырлыгы киңәш иткән төзелеш-монтаж (эш төрләре буенча) эшләренең смета бәяләренең үзгәрү индексы.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының карарларының алыну оештыру, тикшерү һәм алып бару бүлеге